КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.07.2024 № 303-П

Казан

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә урнашкан «Исергап курган каберлеге» ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү, ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән файдалануның чикләрен һәм махсус режимын раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» гы 2002 елның 25 июнендә гамәлгә кергән 73-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» гы 2005 елның 1 апрелендә гамәлгә кергән 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре» карары нигезендә боерам:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә урнашкан «Исергәп курган каберлеге» археологик мирас объектын, әлеге боерыкка караган 1 нче кушымта нигезендә, ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).

2. Расларга:

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә урнашкан «Исергәп курган каберлеге» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясенең чикләрен, әлеге боерыкка караган 2 нче кушымта нигезендә (бастырып чыгарылырга тиеш түгел);

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә

урнашкан «Исергап курган каберлеге» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясен файдалануның аерым режимын, әлеге боерыкка караган 3 нче кушымта нигезендә;

3. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

2024 нче елның 2 нче
июлендә гамәлгә кергән
303-П номерлы
Мәдәни мирас объектларын
саклау буенча Татарстан
Республикасы Комитет
приказына караган
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә урнашкан «Исергап курган каберлеге» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясен файдалануның аерым режимы

Археологик мирас объекты чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында»гы 2002 нче елның 25 нче июнендә гамщлгщ кергән 73-ФЗ номерлы Федераль законында (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон), ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук гражданнарның аннан файдалана алуын тәэмин итү шартларында урманнардан файдалану буенча 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 нчы статьясында күрсәтелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен башкару мөмкинлеген күздә тота.

**1. Рөхсәт ителә:**

мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы биргән рөхсәт (ачык кәгазь) нигезендә археологик мирас объектын өйрәнү эшләрен үткәрү, шул исәптән археологик предметларны эзләү (алу максаты булган эшләрне дә кертеп);

ачыкланган археологик мирас объекты территориясе чикләрендә урманнардан һәм башка эшләрдән файдалану буенча 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән, мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән, археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү турында, яисә археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, йә башкарыла торган эшләрнең археологик мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган коткару археологик кыр эшләрен башкару, проект, җир, төзелеш, мелиоратив, хуҗалык эшләрен башкару;

археологик мирас объектын музейлаштыру чараларын үткәрү;

гражданнарның археологик мирас объектына законнар нигезендә керүен оештыру;

үләннәрне чаптыру, үзлегеннән килеп чыккан агачларны һәм куакларны

кистерү, коры-сарыдан чистарту.

**2. Тыела:**

ачыкланган археологик мирас объекты территориясе чикләрендәге урманнардан һәм башка эшләрдән файдалану буенча 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән, мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән, археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү турындагы, яисә археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итүЮ йә башкарыла торган эшләрнең археологик мирас объектына йогынтысын бәяләүне кертә торган коткару археологик кыр эшләре башкаруны археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү турындагы мәҗбүри бүлекләрне гамәлгә ашырмыйча, эзләнү, проект, җир, төзелеш, мелиоратив, хуҗалык эшләрен башкару;

грунтны, каты һәм башка көнкүреш калдыкларын, шул исәптән төзелеш калдыкларын саклау;

грунтны һәм башка токымнарны алу;

чүп-чар, көнкүреш калдыклары билгеләнгән урыннардан тыш җиргә ташлау.